Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы авылында гражданнар җыены

КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанла авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Сходнево-Чертанла авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Сходнево-Чертанла авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә.

2. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы)юлларны кардан чистарту;

Сходнево-Чертанлы авылындагы юллардагы чокырларны вак таш белән ремонтлау (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3."Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге составына керүче Сходнево-Чертанлы торак пунктында 2018 елның 18 ноябрендәге 2номерлы гражданнар җыены карары нигезендә җыелган гражданнарның калган үзара салым акчаларын Куакбаш авыл җирлеге Сходнево-Чертанлы тапшырылган вәкаләтләргә ярашлы рәвештә, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә, сууткәргеч мөлкәтен тотуга юнәлтү белән килешәсезме?:

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы)юлларны кардан чистарту;

Сходнево-Чертанлы авылындагы юллардагы чокырларны вак таш белән ремонтлау (Пушкин урамы, Азатлык урамы, Кутузов урамы).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, Куакбаш авылы, Карл Маркс урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан җирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы, 5а буенча урнашкан авыл клубы, Чүте авылында Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан авыл клубы бинасында урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова